ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ АПРЕЛЬ * 2020 * КАЗАН

4



Валерий ТАРАСЕНКО

Алмаз ХӘМЗИН

ҮТКӘРЕРБЕЗ!..

Күз кычытса да – вирус,
Арт кычытса да – шул сүз.
Ахрысы, бу дөньяда
Яшәп булмыйдыр ансыз.

Элек ящур бар иде –
Сыерлар авыруы.
Җиңдек карантин ясап,
Булмаса да даруы.

Дуңгыз гриппы чыккач та
Әллә ни искитмәде.
Итен дәүләт кибеттә
Сатты, әрәм итмәде.

Аннан кош гриппы белән
Куркытулар башланды.
Әмма байларыбызның
Күркә булды ашлары!

Инде вәт тагын бер чир
Чыгарганнар дөньяви...
Коронавирус дигән –
Халыкны бик кыра, ди.

Белмиләр нишләргә дә –
Сугышка охшап китте...
Шырпы, сабын, тоз беткән –
Талыйлар бар кибетне.

Хәвеф килгән чакта да
Була сөенүчеләр.
Таҗлы вирустан файда
Алып симерүчеләр.

Куана пенсә фонды
Картлар кимиячәккә.
Шатлана аптекалар,
Карап бай киләчәккә.

Укымыйлар балалар,
Ял итә студентлар.
Вируска сылтый хәзер
МРОТны депутатлар.

Бездә һәрчак могҗиза –
Фаҗигаләр модада.
Модалар үтә-китә,
Үткәребез моны да!

Михаил ЛАРИЧЕВ



СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ...

Күршенең чүкече катырак шакылдый.

Соңгы вакыйгалар һәрвакыт алдагыларыннан начаррак.

Бездә генә, туганнар, дуслар һәм иптәшләрдән башка, «бергә салган идек» дигән танышлар бар.

Беләсезме: организмның кальцийга бер көнлек мохтаҗлыгын каплар өчен кешегә бары тик 26 литр сыра җитә.

Иң төгәл диагноз мәетне яргач куела.

ШОМБАЙ *болай диде...*



Хөрмәтле Чаян! Нәрсә генә дисәләр дә, бездә түрәләр каршында бил бөгү канга сеңгән, аны берничнди дә демократия белән бетереп булмый. Кайчагында ниндидер урта дәрәҗәле начальник тирәсендә дә башлары түбән иелгән ялагай, куштаннар бөтерелә. Күзләрендә бер үк сорау: «Сезнең өчен нәрсә эшли алам, Вәли Вәлиеч?..»

Р. ХӘМИДУЛЛИН

зәй

– **Безнең тормышның асты өскә килгән шул, –** диде Шомбай ага, укучының хатын укып чыккач, – **башың никадәр түбәнрәк иелгән булса, карьера баскычыннан шулкадәр югарырак күтәреләсең...**

Рөстәм ЗАРИПОВ

Языш, уңыш, юыш...

Әдәби ярышта Тукай алыплары, –
Әле Кәҗә җиңү яулый, әле Сарык.
Романга, бәянга уртак калыплары,
Пьесасын да тәпәлиләр шуңа салып...

Кәҗә әйтә: «Микикики, микикики,
Капчыктагы томнарым саны бит унике».
Сарык әйтә: «Күрче, һәр әсәрем көчле,
Икешәр бәйгедә җиңә берсе-берсе...

Шулай итеп, болар яза көне-төне.
Хуплап тора жюридагы җиде бүре;
Ел да уңыш, шуны шәпләп юыш,
Канәгатьлек хисе тоеп, артны уыш...

Эльвира ДЫШАЕВА



Илдар НӘФИЕВ



Телефон уенчылары

Бүген техник үсешнең алгы сафларында барып, яңа мөмкинлекләрне башкалардан тизрәк кем үзләштерә? Әлбәттә, мошенниклар! Мәсәлән, банк карталарының барлыкка килүе булды, шундук шома жуликлар үзләре өчен кешеләрне төп башына утыртуның яңа ысулларын һәм бу юнәлешнең чиксез мөмкинлекләрен ачтылар. Бүгенге көндә пластик карталардан акча урлау – караклыкның иң популяр, заманча төре. Моның өчен кайчагында клиентны ныклап куркытып алу җитә, аннан соң аның белән теләсә нәрсә эшләргә була.

Берзаман Бөгелмәдә яшәүче В. ханымга банкның иминлек хезмәткәре шалтырата. Ул шомлы тавыш белән кемнеңдер аның картасыннан акча күчерергә маташуы турында хәбәр итә. «Нишләргә соң?» – дип өзгәләнә башлый югалып калган хатын. «Банкир» акчаны югалтмас өчен, аны яңа, ышанычлырак счётка күчерергә тәкъдим итә. Башта бераз шикләнеп торса да, ышаныч уятучы көр тавыш һәм махсус финанс төшенчәләре тезмәсе үз эшен эшли: В. ханым ризалык бирә. Нәтиҗәдә, аның банк счётыннан йөз мең сум юкка чыга.

Казанда яшәүче М. белән дә хәлләр нәкъ шундый сценарий буеча бара. Билгесез номердан шалтырату, Россия банклары ассоциациясе «хезмәткәренең» шомлы тавышы, җыелган акчаларны коткару турында тәкъдим... Куркынган ханым «хезмәткәр» киңәше буенча телефонына өстәмә программа урнаштыра һәм код кертә, ә аннан соң аның картасыннан 160 мең сум юкка чыга.

Ярый инде, без – беркатлылар! Күптән түгел мошенниклар Россия Үзәк банкының өлкән экспертыннан 240 мең сум шудырткannар. Гадәттәгечә, «банк хезмәткәре» аңа акчасының юкка чыгу мөмкинлеге турында хәбәр салган һәм «җинаятьне ачар өчен» акчаны башка счётка күчерергә тәкъдим иткән. Закон буенча эш итәргә ияләнгән беркатлы эксперт ханым киңәшне кире какмаган.

Тик кайчагында көр ир-ат тавышлары банк карталары белән уеннарның башка төрләрен дә тәкъдим итәләр. Бөгелмәдә яшәүче бер гүзәлне ниндидер социаль проект менеджеры үзенә караткан. Телефон буенча проектның якты киләчәге турында татлы хикәятләр сөйләп, ул аңа инвестицияләрдә акча эшләргә, ә моның өчен билгеләнгән счётка 40 мең сум күчерергә тәкъдим ясаган. Беренче «транш»тан соң икенчесе – 90 меңлегенә чират җиткән. Аннан соң ике көн эчендә, әкияттәгедәй мул тормыш һәм күз күрмәгән табышлар вәгъдә итеп, ул «инвестор» ханымнан тагын ярты миллион суырткан. Бу уен нәрсә белән тәмамланган булыр иде икән, чираттагы 70 меңне күчергән чакта беркатлы хатынга банктан аның ялганчы корбаны булганлыгы турында хәбәр килеп төшмәсә...


«Карта уеннары»ның колачы таң калдыра. Күптән түгел бер тәүлек эчендә генә җиде татарстанлыны талаганнар. Чаллыда аферистлар, алган дару өчен компенсация түлибез дип, 68 яшьлек пенсионер түтәйне алдаганнар. Ул аларга, имеш, салымнар, страховка һәм банк комиссиясе түлим дип, 117 мең сум күчергән. Әлмәттә 45 яшьлек хатын, акчасы югалудан куркып, мошенникларга ярты миллионын «бүләк иткән»... Мондый вакыйгаларның чиге юк...

Ә бит югарыда китерелгән очракларда акчаны югалтмаска була иде. Бу бик гади эшләнә: төрле «хезмәткәрләр» һәм «менеджерлар» банк картасы мәгълүматлары белән кызыксына башлагач та, сөйләшүне туктатыгыз. Чөнки бу – алдарга теләүчеләрнең төп билгесе. Димәк, сезне төп башына утыртырга телиләр...

Илгиз ИСКӘНДӘРЕВ



Александр АЛЁШИН









• • •

Карт олигарх унсигез яшьлек кызга өйләнә. Дусты аңа әйтә:

– Уйлап кара, ун елдан сиңа сиксән, аңа егерме сигез була бит.

– Булса соң? Аерылам да, тагын унсигез яшьлегенә өйләнәм!

• • •

Табиб, берәүгә шикәр авыруы булуын белдереп, киңәшләр бирә:

– Сезгә баллы, камырлы ризыклар һәм бәрәңге ашарга ярамый, – ди.

– Ә сөешергә ярыймы?

– Хатының белән генә.

– Ә сөяркә белән?

– Ярамый, ул бит татлы...

• • •

Бу дөнья шулкадәрле рәхимсез, хәтта оекбашлар да үзләренең парын таба алмыйлар.

• • •

Хәзерге дәреслекләрнең эчтәлекләренә карагандa, мәктәпләрдәге наркотик куллануларны тикшергәнче, Мәгариф министрлыгында тенту ясау урынлырак булыр иде.

• • •

Район хастаханәсендәге медицина җиһазларыннан бары тик берсе генә – бахил сату автоматы гына эшли иде.

• • •

Унлап телдә сөйләшә белсәң дә, русча белү барыбер кирәк! Аягыңа берәр авыр нәрсә төшүе мөмкин, йә көтелмәгән шатлык килүе...

• • •

Алкоголь нервы күзәнәкләрен үтерә. Бары тик тынычлары, борчымый торганнары гына кала...

• • •

– Кадерлем, сиңа миндә нәрсә ныграк ошый – йөземме, әллә буй-сыныммы?

– Бетмәс-төкәнмәс юмор хисе, җанкисәгем!

• • •

– Официант, кыздырган итегез бик каты.

– Мин аны сезгә кәтлиткә алыштырып бирә алам.

– Мин аны ашый башлаган идем шул.

– Борчылмагыз, кәтлит тә ашый башланган...


Виктор ФЕДОРОВ

Айсылу НУРИЕВА

«ИСӘНМЕСЕЗ!»

Бүген Наилә үзенә игътибар бирмәкче булды. Эштән кайтканда чәчтарашханәгә кереп, чәчләрен рәткә китерде – матурлап кистерде, дулкындай бәдрәләтте. Яшәреп, чибәрләнеп киткән сурәтенә карап, кәефе булып өенә юнәлде. Ире вахта методы буенча Себергә барып эшли. Шушы араларда аның ялга кайткан көннәре. Бәлки, туганнарга кунакка яисә кинотеатрга барып чыгарбыз, дип ниятләде яшь ханым.

Бүлмә ишеген ачуга караватта йоклап яткан иренә һәм иденде тезелеп киткән шешәләргә күзе төште. Аның хәләл җефете, чордашлары кебек, хәмер белән дуслашырга өлгергән. Ял көннәрен үзенчә үткәрергә уйлаган, күрәсең. Наилә пәлтәсен, туфлиен салып куйды, суыткычны ачты, кәстрүлдәге ашны җылытырга әзерләнде. Аның бу эшләрен ире кырын ятып күзәтте. Кәефе кырылган җәмәгате аңа игътибар итмәскә тырышты. Ашны җылытуга ире караватына торып утырды. Хатынының дәшми генә аш бүлгәнен, икмәк кискәнен гаҗәпләнеп күзәтеп утырды да, дәрәҗәле генә итеп:

– Исәнмесез, – дип куйды.

Наиләнең күңеле булып китте, ягымлы елмаеп:

– Исәнмесез, – диде.

Аңа җитди итеп карап торган, чәчләре чәбәләнеп тузгыган иренең кырынмаган, таушалган йөзе бик кырыс иде.

– Ашыйсыгыз килсә, тиз генә ашагыз да китегез, хәзер минем хатыным кайта, – диде ул усал итеп.

Наиләгә кызык булып китте, шулай да ул шикләнебрәк:

– Таһир, ә хатының ни исемле? – дип сорады.

– Наилә исемле, барыгыз, тиз булыгыз!

Стенага карап, ире аңа аркасы белән борылып ятты. Нишләргә белми аптырап калган Наилә киемнәрен киеп урамга чыкты.

Әйе, шул аракы, сыра қолы булу юньлегә илтми. Газиз хатыныңны танымаслык булганчы нигә эчәргә инде? Ә шулай да ихтирам белән "Исәнмесез" диюе күңелгә ятышлы, барлык комплиментлардан өстен иде.

Хөрмәтле ир-егетләр, хәләлләрегезне югалту халәтенә килгәнче эчүне ташлагыз, зинһар. Сез безгә олы йөрәкле, көчле зат булуыгыз белән кадерле. Айнык тормышта матур-рәхәт яшик.


Михаил ЛАРИЧЕВ

ЯРЫЙ ӘЛЕ СИН БАР

Кара төнем уза йокламыйча,
Кара уйлар белән көрәшеп,
Эшкә барам иртән, бар кешегә
Кара карашымны өләшеп.


Кара карга, өч-дүрт кара мәче
Кисеп чыга барган юлымны.
Күз алларым дөм-караңгы, атлыйм
Аералмый уңым-сулымны.

Караңгы йөз белән каршы ала
Компьютерым мине эшемдә.
Дөнья тулы кара эшләрне мин
Рисвай итәм булмәм эчендә.

Кап-караңгы урам буйлап кайтам,
Кара асфальт аяк астымда.
Шомлы кара күләгәләр алда,
Кая гына китеп барсам да.

Синең янда гына, юанычым,
Кара кайгылардан арынам.
Һәр кич кайтып җылы иңнәреңә –
Кара чәчләреңә сарылам...

Ринат АБЗАЛОВ



Вячеслав ШИЛОВ



Игорь КИЙКО



Виктор ФЁДОРОВ



НИШЛӘРГӘ?..

Кадерле "Чаян"! Безнең бистә шәһәр эчендә урнашса да, балалар мәйданчыклары белән әллә ни мактанырлык түгел. Шулай да Боевая урамында балалар мәйданчыгы төзегәч, балалар гына түгел, әти-әниләр дә бик сөенде. Ул мәйданчык юлның икенче ягындагы йорт балалары өчен генә кулай булып чыкты. Ә юлның бу ягында яшәүчеләр өчен бик мәшәкатьле, чөнки юлны чыгарга светофор да, җәяүлеләр кичүе дә юк.

Әлеге үтенечкә шәһәр комитетыннан бик кызыклы җавап килде. Янәсе, юл чатында тротуар, ут яктырткыч баганалар булмау сәбәпле, тиешле таләпләргә туры килмәгәнлектән, мәйданчык әлегә каралмаган дип аңлаттылар... Күрәсең, шуңа ясамыйлар. Икенче якта боегып утырган балаларга гына моны ничек аңлатасы?..

Игумново бистәсе әти-әниләре.

КАЗАН

ЮКӘЛЕ МӘСЬӘЛӘ

Кадерле "Чаян"! Күптән түгел шәһәр үзәгендәге К. Маркс һәм Зур Кызыл урамнарында шаулап үскән йөзләгән юкәләр яшелләндерүчеләр балтасыннан харап булдылар. Шуны әйтеп үтәсем килә: анда яшисен яшәгән агачлар гына түгел, ә яшь агачлар да кырылды. Аларча, шәһәрне яшелләндерүнең яңа ысулына бу туры килеп бетми икән... Шул тирәдә яшәүчеләр бик моңсуланып калды, чөнки аларга бозык һаваны әле озак сулыйсы.

Ә Мәскәү белән Петербург калаларының тәҗрибәсенә таянсалар ничек булыр иде икән? Алар агачларны кисkәнче элек дәвалап карыйлар, кискәч нәрсә буласына экологик нәтиҗәләр ясыйлар, һәм шуннан соң гына ниндидер карар кабул итәләр. Ә бездә исә башта кортабыз, аннан уйлыйбыз!


Инде иске агачлар урынына яңаларын утыртып чыктылар. Бер рәткә тезелгән солдатлар сыман. Безнең әле истә: Ленин дамбасыннан кисеп аткан агачлар урынына утыртылган яңа үсентеләрне күпме генә тырышсалар да, үстерә алмадылар – киптеләр, корыдылар. Шундый ук язмыш көтелмиме икән шәһәрнең тарихи өлешендә дә?

Л. РАХМАНОВА

КАЗАН

КӨЛКЕ КАМЕРАСЫ





Игорь КИЙКО



Виктор ФЁДОРОВ



Валентин ДРУЖИНИН

Шәһәрдә тынлык...

Александр БРЮХАНОВ

Кичә 7 нче Ватык юл урамында ике иномарка бәрелешкән. Машина йөртүчеләрнең икесе дә исерек булган, һәм шунда ук кемнең ныграк исерек булуын ачыклый башлаганнар... Урамнан узып барган туташ аларны аерырга тырышып караган, ләкин ул үзе дә бигүк аек булмау сәбәпле, берни барып чыкмаган. Бәхеткә, бу урыннан машинасында кичә генә полициядән эштән чыгарылган хезмәткәр узып барган. Ул кызны читкә алып китеп, көчләп машинасына утыртырга маташкан. Кыз кычкыра башлагач, бәрелешкән машиналарның хуҗалары аны коткарырга ташланган... Шул вакытта монда килеп туктаган автобустан «салмыш» гражданнар бүселеп чыккан һәм аларны аера башлаган. Нәтиҗәдә, барысы да бер-берсе белән сугыша башлаган. Бәрелештә тын шәһәрнең тынычлыгын бозучыларны өнәп бетермәүче ара-тирә узып баручылар катнашып алган. Аларга тавыштан кәефләре кырылган кәеф-сафа коручы күрше йортларда яшәүчеләр барып кушылган. Аннан соң янәшәдәге «Чәкүшкә» кафесында нәчәлникларының туган көнен билгеләп утырган ОМОН килеп, сугышучыларны ныклап «кочаклый» башлаган. Бу назлардан соң аягында тора алганнарны кафега чакырып, алар белән тәрбия эшен дәвам иткәннәр... Килеп җиткән «Вакыйга» телепрограммасы корреспондентлары бу хәлне камерага төшерә башлаган, ләкин аларның барысы да кәефле булу сәбәпле, сугышучыларны фокуска тота алмаган. Ярый әле узып барган «ашыгыч ярдәм» санитарлары барысын да машиналарына төяп, ясалма сулыш һәм тынычландыра торган укол ясап, билгесез юнәлештә алып киткәннәр... Ә бәрелешкән машиналарны каядыр эвакуатор алып киткән, тик иртән эвакуатор йөртүче кая икәнен исенә төшерә алмаган... *Ә шәһәрдә яңадан тынлык хөкем сөрә* башлаган, һәм җирле хакимияттә соңгы тостларын шуның хөрмәтенә күтәргәннәр. Нишлисең бит, мондый хәлдә бу аларның бердәнбер эшли алырлык гамәлләре булган.

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Ялганның өч төре бар: ялган, оятсыз ялган һәм статистика.

Тәрбиялелек – уйларыбызның әйтелмичә калган өлеше.

Табигый булу – бик уңайсыз халәт: озак түзеп булмый.

Хатыннар җиңелгәннәрне яраталар, ләкин аларга җиңүчеләр белән хыянәт итәләр.

Хатын-кызлар матуррак картаялар.

Халыкара килешенүләрнең иң ныклы өлеше булып кәгазь кала.

Бер генә ярсу теләкне дә башка кешенең кульязмасын төзәтү теләге белән чагыштырып булмый.

Яхшы һәм киң күңелле кешенең, дусларының кәефен бозмас өчен, берничә нәни җитешсезлеге булырга тиеш.

Сәбәпсез алдамаган хатыннарны эчкерсез дип саныйбыз.

Мәсьәләнең хөкүмәт тарафыннан чишелүе аны катлауландыра гына.



Александр ШУЛЬПИНОВ









Дамир МОРТАЗИН

РӘХМӘТЛЕ ЭШ

Участок табибы, кабул итүен тәмамлау белән, як-ягына карап алды да, өстәл астыннан кибет пакетын чыгарып, кыюсыз гына миңа сузды.

– Рәхим итеп, алыгызчы! – диде.

– Нәрсә бу? – дип гаҗәпкә калдым.

– Коньяк белән конфет...

"Мәкерме әллә инде бу... Гадәттә, киресенчә була торган иде... Бәлки, яшерен камера белән төшереп торалардыр..." – дип уйлап алдым, ләкин пакетка орынмадым.

– Алыгыз, ал! – диде табиб. – Сезгә бу рәхмәт йөзеннән...

– Ни өчен? Мин бит сезгә бернәрсә дә эшләмәдем...

– Менә шуның өчен дә сезне хөрмәтлим... – дип, минем аптырап калуыма ачыклык кертте ул.

– Беләсезме, соңгы вакытларда монда килүчеләр артык шикле була башладылар. Һәрнәрсәдән мәкер эзлиләр. Йә мин аларга алай карамаган, йә әкрен кабул итәм, йә тиз тикшерәм... Куелган диагнозларга ышанмыйлар – интернеттагыны күбрәк чагыштыралар. Ул, Аллам сакласын, әгәр кыйбатрак дару язсам – беттем, мафия, аптекалар белән бергә килешеп байыйбыз! Гомумән, ниндидер шикләнүләр – шундук горздравка, прокуратурага шикаятьләр язалар, социаль челтәрләргә таратталар... Шуннан соң тикшерүләр, аңлатмалар, шелтәләр, премияләрне кисүләр китә...

– Минем моңа ни катнашым бар? – дип бүлдем мин табибның зарлы сөйләвен.

– Сез бит күзәтүләрем буенча өч елдан артык бер генә дә шикаять язган кеше түгел минем өстән! Безнең заманда бу, ышаныгыз, бик сирәк нәрсә... – диде дә зур ихтыяр белән кулыма пакетын тоттырды. – Алыгыз, ал, күгәрченем, һәм минем исәнлегем өчен берәр рюмка чүмәлтегез. Ул миңа шулхәтле кирәк!.. Сәламәтлекне әйтәм.





КИЕРЕНКЕ ХӘЛНЕ ИСТӘ ТОТЫП

Чаллыда яшәүче бер үткен бәндә гадәти булмаган бизнес уйлап чыгарган. Дөньядагы киеренке хәлне истә тотып, ул бомбоубежище төзергә булган. Бу планын тормышка ашыру өчен ул хәзер инвестор эзли. Бункерның күләме зур түгел – бары тик 25 кешелек, ә бер урынның бәясе 15 миллион сум. Беренче сатып алучы өчен кызыксындыру чарасы да каралган – ул бүләк сыйфатында өстәмә дүрт урын ала. Корылманың төгәл урнашу урыны хәзергә сер булып саклана, әмма аның Чаллыдан ерак булмаганлыгы билгеле инде.

ЭШ СӨЮЧӘН ДЕПУТАТ

Чирмешән депутатларының берсе узган елның декабрендә исерек килеш руль артында тотылган. Халык мәнфәгатьләрен яклаучыны суд аны 200 сәгатьлек мәҗбүри эшләргә тарткан. Өстәвенә, закон буенча аның вәкаләтләре дә вакытыннан алда туктатылырга тиеш булган. Ләкин җәзага тартылган дәүләт әһеле эшчәнлеген туктатмаган һәм эшкә йөрүен дәвам иткән. Тик суд карарына буйсынмау эзсез үтмәгән. Башта депутатны мандатыннан мәхрүм иткәннәр, ә аннан соң 22 көнгә колониягә сөргәннәр.

ДУСЛЫК ХАКЫНА ЗЫЯН

Арча районының Иске Чүриле җирлегендә башлык булып торган ханым чиктән ашкан дуслык хисләре аркасында хезмәт урынын законсыз файдаланган. Ул социаль найм буенча чиратта торган өч кешене учёттан төшергән һәм моңа хокуклары булмаган дуслары белән килешенү төзегән. Соңрак алар бу торакларны үз милекләре итеп теркәгәннәр. Бу дуслыктан китерелгән зыян 1,9 миллион сум тәшкил иткән.

КАЙНАР КАНЛЫ ГҮЗӘЛ

Чаллы шәһәренең юл-транспорт очраклары теркәү үзәгенә авариядән соң 21 яшьлек кыз килгән. Тикшерү вакытында аның «салмыш» булуы, өстәвенә, машина йөртү хокукы таныклыгының ялган икәнлеге ачыкланган. Җилбәзәк туташ исерек килеш рульгә утырган өчен ел ярымга йөртү хокукыннан мәхрүм ителгән булган, ләкин тимер дусты белән аерылырга теләмәгән. Авария буенча беркетмәдән башка, тагын берничәне төзергә туры килгән.










Олег ПРЯНИЧНИКОВ

Кәйсез Мадам Клико

Мин эшләгән шәраб заводының хуҗасы 8 Март бәйрәме алдыннан акча эшләп алырга булды. «Шампанский чыгара башлыйбыз, – диде ул, – һәм тегенди-мондыен гына түгел, ә бөтен дөньяга дан тоткан «Мадам Клико» маркасын гына! Житәр гүзәл затларыбызны болганчык сыекчалар белән агуларга!» Без, шәраб житештерү осталары, шатланып риза булдык. Өчәр смена эшлибез. Эшләр гөрләп бара – затлы эчемлекне килеп торган машиналарга төяп җибәрергә көч-хәл белән өлгерәбез. Тик көтмәгәндә «Мадам Клико» акылыннан язды диярсең – әле тегендә шешәсе шартлаган, әле монда бөкесе аткан. Тиздән сатып алучылар зарлана башлады – кем шартлавына, кем исенә... Бераздан яңа товар, гомумән, сатылмый башлады диярлек. Житештерү күләмнәре төште, табыш кискен рәвештә кимеде. Килгән зыянны исәпләп чыгаргач, хуҗа житештерү бүлеге мөдирен чакыртып алды. Ярсыган мөдир технолог һәм дегустаторның тетмәсен тетте: «Нишләп минем «Мадам Клико» шартлый?!» – дип жир тетрәтте хуҗа, чираттан тыш киңәшмә җыеп. Мөдир, технолог һәм дегустатор гаепле кыяфәт белән күзләрен идәнгә төбәделәр. Шунда кинәт житештерү бүлеге мөдире аваз салды: «Бәлки, эш һава температурасындадыр?» «Әйе! Нәкъ шулай! – мөдир йодрыгы белән маңгаена суккалап куйды. – Эссе шул бездә...» «һәм корырак та», – дип өстәде дегустатор, читкә таба суларга тырышып. «Димәк, күченәбез!» – дип ярып салды хуҗа. һәм шулай эшләделәр дә. Хәзер яңа шампанский башка торак йортның подвалында житештерелә. Монда мәңге тамып торган канализация торбаларыннан ел буе салкынча һәм дымсу. Кәйсез «Мадам Клико» өчен нәкъ шул кирәк тә инде.

Валерий ТАРАСЕНКО



Александр СЕРГЕЕВ



Вячеслав ШИЛОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Максим СМАГИН





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

– Кадерлем, – ди хатын, – безнең күрше хатынның туны нәкъ минеке төсле.

– Һәм мин сиңа яңа тун алып бирергә тиешме?

– Яңа фатирга күченеп китүгә караганда бу барыбер арзанрак була бит...

• • •

Ниһаять, санкцияләр безнең Рәсәйдәге гади халыкка да кагыла башлады: урамнар тишек-тошыклы джинсы кигән халык белән тулы.

• • •

– Доктор, минем корсагым кабарды.

– Әйе, сез йөкле.

– Ә-ә, шулайдыр әле ул, эчәм-эчәм – эспумизан ярдәм итми.

• • •

Укытучы:

– Сукыр тычкан һәр көнне үзенең авырлыгы кадәр ризык ашый.

Укучы:

– Ә ул үзенең авырлыгын каян белә соң?

• • •

– Мин җәйгә дип бераз акча җыям әле.

– Нәрсә, хәзер җәй дә түләүлемени?

• • •

– Кадерлем, анда ниндидер кеше килгән, ул үзен синең бертуганың ди, һәм шуны исбатлый да ала.

– Шыр тиледер ул!

– Әлбәттә! Ләкин аның башка дәлилләре дә бардыр дип уйлыйм.

• • •

Балачакта мин бик еш пластмасс уенчыкларны чәйни идем. Тәме әле дә хәтеремдә. Хәзер «Пятёрочка»дан алган помидорларны ашыйм да, шул вакыттагы рәхәтлеккә чумып утырам...

• • •

– Әй, нәрсә минем кесәдә актарынасыз?

– Мин анда шырпы эзли идем...

– Нәрсә сорап булмый идемени?

– Сезне шырпы өчен генә борчыйсым килмәде...

• • •

– Син хәзер кем белән исәнләшеп уздың?

– Ул – минем икенче иремнең беренче хатынының өченче ире.

АБАУ!

КҮГӘРГӘН ТӘҢКӘ

2016 елны Россия валютасының 700 еллыгына Ульяновск шәһәренең кызыклы фәннәр музее 1 сум акчага һәйкәл урнаштырган. Арт-объект күгәрми торган корычтан эшләнгән, 50 мәртәбә зурайтылган тәңкә һәм "Безнең бер сум күгәрми" дигән оптимистик язу белән бизәлгән. Тик лозунгка карамастан, 1 тәңкә күгәрек белән капланган, соңгы вакыттагы яңалыкларга карасаң, бу бик гыйбрәтле булып чыга. Акча сынын коткарачаклар – сүтәчәкләр һәм реставрациягә алып китәчәкләр. Икъдисадта да бөтенесе дә шулай җиңел булмавы кызганыч.

ҮЗ ҮРНӘГЕ

Кузбасcның Карагайлинский поселогында кайбер яшәүчеләр краннан аккан суда суалчан тапканнар. Тиздән администрация дезинфекция үткәрү һәм проблема чишелүе турында отчет биргән. Тик суалчаннар үткәрелгән эшләрне үзләрендә сизмәгәннәр һәм бөтен поселокның краннарына үтеп кергәннәр. Ачулары кабарган яшәүчеләр шакшы суны шешәгә тутырып администрациягә алып килгәннәр. Киселевскның коммуналь хуҗалык буенча җитәкче урынбасары Сергей Шишкин крандагы су чиста дип белдергән һәм яшәүчеләр алып килгән суалчанлы суны эчкән. Килүчеләр шаккаткан, тик урынбасарга карап суны эчәселәре килмәгән һәм прокуратурага мөрәҗәгать әзерләгәннәр.

АРБАЛЕТ БЕЛӘН

Чиләбе өлкәсенең Озерск шәһәрендә ашыгыч ярдәм күрсәтү станциясенә һөҗүм иткәннәр. Арбалет белән коралланган дүрт ир медиклардан иптәшләренең бәвел һәм кан анализларын таләп иткәннәр. Алдагы көнне аны руль артында исерек килеш тоткан булганнар. Тик табиблар тикшереләчәк үрнәкләрне батырларча сакларга ташланганнар. Нәтиҗәдә, ике табиб – шифаханәдә, ә дүрт талаучы – рәшәткә артында. Анализлар зыян күрмәгән.

ИНВЕСТИЦИЯ ЯКИ ҖАН

Индия гражданины өчен кияүгә чыкмаган Мәскәүдә яшәүче ханым белән очрашу котылгысыз булып чыга. Танышканнан соң ханым "кавалерны" өенә чакырган. Тик романтик кич урынына чит ил кунагын коралланган ират көткән. Пистолет көпшәсе терәгән килеш, аны фатир хуҗабикәсе белән булачак никах һәм аның бизнесына 5 млн. сум инвестиция ясарга дигән кагазьләргә кул куярга мәҗбүр иткәннәр. "Кияү" кире уйламасын өчен, аны бәдрәфтә бикләп тотканнар. Өйләнешү церемониясеннән соң яңа өлгергән ир һәм инвестор полициягә мөрәҗәгать иткән.



– Әкият тормыштан нәрсә белән аерыла?

– Әкияттә бакага өйләнәсең, ә ул гүзәл патша кызына әверелә. Ә тормышта – киресенчә...

Валерий ТАРАСЕНКО



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Николай ВОРОНЦОВ



Бөтен нәрсәсе булган, тук һәм көр олигарх пляжда кызынып ята. Күрә – суда алтын балык йөзеп бара. Ул аны кулы белән тотып ала:

– Әйдәле, тиз генә миңа өч теләк уйлап тап!

Эльвира ДЫШАЕВА



Валерий ТАРАСЕНКО



БЕЗГӘ ЯЗАЛАР

Арча районының Яңа Кенәр авылында яшәүче Марат Абдуллиннан хат.

Без ике ел башка авылда яшәдек. Әти шунда сельпо рәисе булып эшләде. (1939-41 нче еллар). Аннан аны икенче сельпога күчерделәр. Күченеп йөреп, бәрәңгене дә 17 июньдә генә утырттык. Уңышы гадәттәгечә булды.

Шура авылында торганда мин сельподан иске "Чаян"нарны алып кайта идем. Битләрен стенага обой урынына ябыштырам, иртән юынырга килгәч, язылган җирләрен укыйм, онытылып китеп, ашарга утырганда да шуларны көлемсерәп уйланам. Инде күбесен ятлап та бетердем. Хәзер берничәсен язып җибәрәм. Ул истәлекләр әле дә актуаль.

Ә бу шигырьләрне сеңлем Сәвия концертта укый иде – халыкның эче катып көлгәнен белсәгез?!

Столовой почмагында
Бер ят әйбер күргәннәр...
Кырып, тырнап, юып кына
Сөлге икәнен белгәннәр.

Монысы шапшаклыкка тәнкыйть булгандыр.

Киемем начар –
Йөрәгем саф, аның каравы.
Киемем яхшы –
Ләкин йөрәгемнең
77 төрле ямавы.

Ул заманда яңа телогрейка затлы кием булып күренә иде.

Әйдә, энем Әхмәди,
Атларны ку, тиз барыйк.
Беренче бюллетеньнарны
Карчык белән без алыйк.

1936 елны беренче тапкыр Югары Советка сайлау бәйрәм төсендә узды. Шушы шигырьгә бәйле рәсем дә бар иде. Йөзләрендә – шатлык!

Сугыш вакытында "Чаян" чыкмый торды. Ләкин "чаянчылар" төрле газеталарда сатира-юмор язмаларын, рәсемнәрен чыгарып тордылар. Менә ике карикатураның эчтәлеге: бер немец солдаты тылга элдертә. Аркасында совет солдатының кирза итегенең табаны ярылып ята. Безнекеләр типкән эз. Тагын бер немец солдаты бил каешына яңа тишек ясап утыра. Аста язу: "Норма һаман кисел, каеш һаман тишелә". Ягъни солдатларны начар ашаталар.

Сугышка кадәр чыккан бер сандагы хикәя искә төште әле. Имеш, Казанда бер ашханәгә ашарга кергән кешеләрне үлчәп кертәләр икән. Чыкканда тагын үлчәп, аерманы түләтәләр ди. Берәү, боларны кызык итү өчен, кесәсенә кирпеч салган килеш үлчәнгән. Ашап бетергәч, аны өстәл астына шудырган. Тегене үлчәп карыйлар – ә ул ашханәгә кергәннән дә җиңел. Аерманы клиентка түләгәннәр, имеш.

Иван ХАНТИМЕРОВ, «Чаян» № 5, 1994



– Калдырып киткәннәр моны! Әнә, язуы да бар!

Виталий ФЕОКТИСТОВ, «Чаян» № 23, 1998



Ринат АБЗАЛОВ



Безгә фото җибәргәннәр,
Менә болай дип язып:
«Пенсиябез болай да аз,
Җитмәсә, идән ярык –
Акчаны булмый алып».



Рузалия ШӘЙДУЛЛИНА

Илзирә ВӘЛИУЛЛИНА

КОРОНАВИРУС

Нинди генә хәлләр булмый
Тормышта, бу заманда...
Коронавирус Covidтан
Бар халык пошаманда.

Кеше куплап йөргән җиргә
Ярамый, ди, барырга.
Даруханәләрдә чират
Кирәк-ярак алырга.

Маска – битлекләр никтер юк –
Мыскыл кебек бу... кызык...
Бу уңайдан хөкүмәтне
Сүгәләр кызып-кызып...

Карантин көтелә диеп
Хәбәр-оран салалар.
Шуңа күрә кибетләрдән
Куплап азык алалар.

Мәдәният чаралары
Концертлар күчерелә –
Тыныч яшәгән халыкның
Күңеле төшерелә.

Бу хакта бар дөнья шаулый
Хәбәрләр купкә китте.
Кешене хафага салма,
Коронавирус, җитте!

Ошбу шау-шудан, билгеле,
Беркем түгел канәгать.
Канәгатьлек – иң зур вирус,
Буыйк шуны, җәмәгать!

Юрий КУХАРЕНКО







Тиктомалдан Ләбибнең депутат буласы килеп китте. Житмәсә, Камил белән мине дә булышырга кыстый.

– Алмаз, син мондый эшләрдә "песи ашаган" кеше, жаен беләсең, – дип, салпы якка салам да кыстыра. Матур итеп үгетләүләренә эреп китәрсең, билләһи. Зур максатлар куйган алдына. Житәр, ди, илебез һәлакәт алдында тора, ягъни икътисад үсми, халыкның тормыш шартлары начар, хезмәт хаклары түбән, фәлән-фәсмәтән... "Кара инде, – дип җиппәрә, – МРОТның мескенлеген, мондый хезмәт хакына бит кешеләр "УМРУТ", – дип куя, димәк, халык кырылып бетәчәк. Шагыйрь булгач үзе, рифманы таба белә инде ул.

– Менә, мәсәлән, – ди, – синең зарплатаң күпме?

– Тугыз мең, – мәйтәм, – ярты ставка.

– Соң, шулай булгач, син "байлар долой!.." – дип, демонстрациягә чыгарга тиеш. Әйдә, минем белән, һичьюгы "доверенный" булып йөр, ул тугыз меңне үзем түләрмен, – ди.

– Каян синең акчаң булсын? – мәйтәм.

– Табарбыз. Спонсорлар бирер...

Беләм бит инде, алар башта шулай, эшең уңмаса – барысы да шылай.

Ярар, Ләбиб дигәндә, аяк идәндә!.. Киттек, өчәү илне бәладән коткарырга! Минзәләдән башлыйбыз. Вакланып тору юк – район главасына керәбез. Кабул итә – итми карасын! Аларга "күрсәтмә" күптән килгәнен беләбез, ләкин бездәйләргә уңай түгел ул. Главадан ачык йөз, сөтле чәй дигәндәй. Әмма чәе булмады. Фатихасы әйтелде. Безгә карап, шаккатуы күренде. Йөрсеннәр, халыкка культуралы хезмәт күрсәтсеннәр, чүтеки данлыклы кешеләр диеп, безгә бәя бирелде.

Беләбез, ул – югарыдагылар фәрманы корбаны, аларның теләгән йөз процент үтәүче.

Бу районда атна-ун көн йөргәнбездер... өметсезлеккә бирелгән халык күңелен күтәреп. Рәхмәттән башка сүз ишетмәдек. Тик ләгънәтләр яуды, безнең адреска түгел, моңарчы күренмәгән кандидатларга – ягъни сайланачак буш куыкларга.

Аннан китек Мөслимгә. Кабул итте башта глава. Эше бара икән бик яхшы, ничек гөнаһ эшләсен, ди, аңа халкы каршы?.. Тыңлый сүзен, үти эшен. Без дә тойдык аннан бу хисне, чыктык булмәсеннән эчеп сөтле чәйне. Йөзендә – нур, бездә дә шул. Озатты өчебезне хәер-фатихасы белән очрашуларга зур. Матур йөрдек, ни дисәң дә, Ләбиб депутатлыкка лаек! Гөрләп торды авыл, район клублары, әле дә колак төбендә шаулый алкышлары.

Инде Актанышка чират. Тотып булмый урынында һич главаны, эшләмичә тормыйбыз көтеп аны. Дуслар күп безнең монда, беләләр Ләбибне, Камилне һәм мине. Чакырып торалар авыл саен очрашуга, житешеп булмый әйләнеп чыгарга барысын, житә сайлау көне.

Ниһаять, глава да аваз салды, чакырды биек бинасына. Чәйләр эчертми генә, алып китте өчебезне балалар лагерена. Зур мәйданда байрак күтәрештек, жыелышу уңаеннан, өченче сменага. Ялкынлы сүзләр сөйләдек, бөтен мәйданны ярып, кемнәр безнең кебек Бөек булмас, моннан соң лагерьда ял алып. Ә соңыннан сыйландык, главасыз гына бик кыйбат!.. Бер көннән соң сайлау була – беләбез, кем депутат! Ничек инде белмисең, ди... Альтернатив бар иде. Бер күренмичә халыкка, күкрәк кагып йөрде. Имеш, иң зур Дәү киңәшче үзе аңа фатиха биргән! Ләбиб күп тавыш жыйса да – аңа шагыйрьлек житкән!

Бу гамәлнең морале – сайлау түгел – санап карале!

Нигә, нигә һаман шулар
Сайлана парламентка?..
"Сөт тә юк болардан, май да", –
Диләрме әле халыкта?
– Алар күкәй салмый торган
Охшаган бит тавыкка!

Алмаз ХӘМЗИН



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 4 (1893) апрель 2020
Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА


«Татмедиа» басма матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылып алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 02.04.2020 ел.
Тираж –1288 Заказ А-666
Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле
16+

СӘЕР КЕШЕЛӘР

Валентин ДРУЖИНИН



Игорь КИЙКО



Михаил ЛАРИЧЕВ



Виктор ФЁДОРОВ





